СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«28» сентябрь 2018 ел** **№ 53**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетының «референдум үткәрүне оештыру турында» гы 2018 елның 24 сентябрендәге 11 номерлы карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советының «референдум үткәрүне оештыру турында» гы 24.09.2018 елгы 52 номерлы карары нигезендә Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:
   - Иске Чүриле авылы Яңа урамына янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру;
2) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

**- т. п. юл-урам челтәрендәге вак таштан юл полотносын каплау:**
-Иске Чүриле авылы, Яшел урамы, 8 нче йорттан алып Мәктәп урамы, 82 нче йортка кадәр;
- Иске Чүриле авылы, Яшел урамы, 22 нче йорттан алып Мәктәп урамы, 44 нче йортка кадәр;
- Иске Чүриле авылы, Яшел урамы, 52А йортыннан яңа урамга кадәр, 19;
- Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 34 тән 48 гә кадәр;
- Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 13 тән 14 кә кадәр;
- Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 16 йорттан башлап Яңа ур., 12 йортка кадәр;
- Штерә авылы, Совет урамы, 52 дән 93 кә кадәр;

- **торак пунктта юл-урам челтәренең грунт-вак ташыннан нигез салу:**
- Иске Чүриле авылы, Зеленая урамы, 63 йорттан 65 кә кадәр;
- Иске Чүриле авылы, Матросов урамы, 4 тән 20 гә кадәр;
- Венета авылы, Үзәк ур., 20 дән 28 кә кадәр

Экономияләнгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә

ӘЙЕ ЮК

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 52; ТР, Арча районы, Штерә авылы, Совет ур., 30; ТР, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4а; ТР, Арча районы, Венета авылы, Мәктәп урамы, 3.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина

СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ